




***Яүширмәгә янә кайттым әле,***
***Гомерләрем күзгә авышкач.***
***Күзләремне яшь пәрдәсе сарды,***
***Туган авылым белән кавышкач...***
***Ф.Тарханова.***

***Даның җырга күчә бара,***
***Чистаем- гүзәл калам,***
***Исемеңне ишетсәм дә,***
***Җаныма сихәт алам...***







Авылыбыздан Бөек Ватан сугышына 500 кеше китә.




*Сугышка киткән ир-егетләребезнең 300 дән артыгы туган авылына кире әйләнеп кайта алмый...*



СОЮЗ СОВЕТСКИХ СОЦИАЛИСТИЧЕСКИХ РЕСПУБЛИК

ГЕРОЮ СОВЕТСКОГО СОЮЗА

ПРЕЗИДИУМ ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР УКАЗОМ от „16“ мая 1944 г. за образцовое выполнение боевых заданий командования на фронте борьбы с немецкими захватчиками и проявленные при этом отвагу и геройство ПРИСВОИЛ Валиеву Леониду Геонаевичу ЗВАНИЕ ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА.

Председатель Президиума Верховного Совета СССР

Секретарь Президиума Верховного Совета СССР

Москва — Кремль, 23 декабря 1966 г.



Советлар Союзы Герое Вәлиев Габделәхәт Габделганиевич





*Геройның тормыш иптәше Фәрдана, улы Рәшит, килене Ясирә.*

**Советлар Союзы Герое Габделәхәт Вәлиевның туган авылында яшәүче хатынына язган хатлары. Хатлар гарәп телендә язылган. Улы Рәшит, килене Ясирә аларны татар теленә тәрҗемә иттергәннәр, хатларның төп нөхсәсе туган нигезендә саклана.**


Выше черты не писать

Ниже черты не писать



Габделәхәт Вәлиевның оныклары:
Әнәс, Минәхмәт, Мөнирә, Нургаен



Геройның улы Рәшит
һәм оныгы Әнәс




Герой шәһәр Севастопольне азат итkәндә 241 кешегә Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Геройның улы Рәшит әтисенең фамилиясе янында.





*1975 нче ел. Севастополь.*
*"Туганнар каберлегендә"*

***Рәшит абый тормыш иптәше Ясирә апа белән геройның каберлегенә барып туфрак алып кайтып, полкташлары белән һәрдаим хәбәрләшеп, хатлар язышып , аралашып тордылар.***



Бүгенгесе көндә Яүширмә авылында геройның оныклары матур гына гомер итәләр.



Килене Ясирә Нургали кызы оныклары белән

Без беләбез, бабабызга,
Бирелгән бит Герой исеме.
Онытмабыз...
Туган иле, туган халкы өчен
Җанын фида кылган изге кешене.



# Советлар Союзы Герое
# Шамсетдинов Гали
# Нурулла улы



Пролетарии всех стран, соединяйтесь

СССР

ДИПЛОМ



ДЕЛО № 129

Шамсутдинова Гали Нурулловича

Начато 1932 г.

Окончено 1936 г.



**1932 нче елда авыл хуҗалыгы институтына укырга керә, 1936 нчы елда тәмамлый.**



# Герою Советского Союза

Союз Советских Социалистических Республик

Тов. Шамсутдинову Галею Нуруловичу

За Ваш геройский подвиг, проявленный при выполнении боевых заданий командования на фронте борьбы с немецкими захватчиками, Президиум Верховного Совета СССР своим Указом от 23 сентября 1944 г. присвоил Вам звание Героя Советского Союза.

Председатель Президиума Верховного Совета СССР

Секретарь Президиума Верховного Совета СССР А. Горкин

Москва—Кремль, 21 июля 1947 г.

№ 6842



КОПИЯ

ПРЕЗИДИУМ ВЕРХОВНОГО СОВЕТА

Москва - Кремль 1 ноября 1947 г.

ШАМСУТДИНОВУ Нурулле

Уважаемый товарищ Шамсутдинов!

По сообщению Военного Командования Ваш сын гвардии лейтенант ШАМСУТДИНОВ Галей Нуруллович в боях за советскую Родину погиб смертью храбрых.

За геройский подвиг, совершенный Вашим сыном Галеем Нурулловичем Шамсутдиновым в борьбе с немецкими захватчиками, Президиум Верховного Совета СССР Указом от 23 сентября 1944 года присвоил ему высшую степень отличия - звание ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА.

Посылаю Вам грамоту Президиума Верховного Совета СССР о присвоении Вашему сыну звания Героя Советского Союза для хранения как память о сыне герое, подвиг которого никогда не забудется нашим народом.

Председатель Президиума Верховного Совета СССР
( Н.Шверник )

Копия верна



***1944нче елның 22 июлендә Гомулец авылы янында лейтенант Шәмсетдинов үзенең танкларын сугышка соңгы тапкыр алып бара һәм шул көнне ул геройларча һәлак була. Ике ай үткәч,1944 нче елның 23 сентябрендә, гвардия лейтенанты Гали Нурулла улы Шәмсетдиновка Советлар Союзы Герое исеме бирелә.***

## Сугыш юлын үткән гаярь затлар…

Татарстанның Чистай районыннан яшь авыл укытучысы Гали Шамсетдинов армияга 1939 елда алынды һам сугышны тәҗрибәле солдат булып каршылады. Гали хезмәт иткән часть канлы сугышларда һөҗүм итуче дошманга нык каршы торды. Шулай да гитлерчылар көнчыгышка һаман ераккарак үтеп керделәр… Әнә шул авыр көннәр Шәмсетдиновның хәтерендә мәңгегә калды, һәм ул илбасарларның совет җиреннән нык кыйналган килеш качканнарын күрәчәгенә ышанычын югалтмады.

Изге теләк ике елдан соң үтәлде. Хәзер ул офицер-танкист иде. Шәмсетдинов фашист танкларын Курск дугасында җимерде һәм чигенүче немец гаскәрләрен Днепрга кадар эзәрлеклэп барды. Аның танк ротасы киң елганың уңъягына беренчелардән булып чыкты һәм анда дошман танкларының , пехотасының контратакаларына каршы торды.

Биләгән плацдармнарыннан һөҗүмгә күчеп, гвардияче танк частьлары немецларның каршылык күрсәтүен сындырдылар һәм 1943 елның 6 ноябрендә Киевка керделәр. Украина башкаласы янында Шәмсетдинов яктыртылган фаралар белән мәгълүм төнге атакада катнашты.Үз окопларына таба куәтле ташкын булып килә торган күз чагылдыргыч йөзләгән уттан, бик куп танклар атуыннан һәм алар артыннан җиңүчән «ура» кычкырып килган пехотадан гитлерчылар бөтенләй югалып калдылар. Шәмсетдиновның танкысы, немец ныгытмалары полосасына ыргылып кереп, берничә орудиене һәм пулеметны таптап үтте, уннан артык фашистны атып үтерде.

Бу сугышлар өчен Гали Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде. Батальон командиры шул вакытта: “ Гвардия лейтенанты Шәмсетдинов Днепр аша чыкканда һәм Киевны алганда үзен батыр һәм нык ихтыярлы командир итеп күрсәтте, шәхси үрнәге белән уңышка ирешүгә булышлык итте”, - дип билгеләп үтте.

... Һөҗүм 14 июльдә башланды. Коры җир гаскәрләренең һәм авиациянең берләштерелгән ударлары белән киң булмаган урман участогында дошман оборонасы өзелде, шунда танклар бәреп керде.

Өзелгән урынның киңлеге 5-6 км. гына иде, ләкин гвардиячеләр һәр ике ягыннан фашист дивизияләре сугыш хәрәкәтләре алып барган тар коридорга кыю рәвештә килеп керделәр.

Гитлерчылар өметсезлек һәм тәвәккәллек белән әле бер якка, әле икенче якка ташландылар һәм танкистларны тоткарларга омтылып карадылар.

Хәрәкәт планын Гали бик тиз уйлады. Юлдан читтәрәк куаклыклар белән капланган борылмалы иңкүлекне күреп алып, ул ротасын шунда алып китте. Танкистлар өчен немецлар уты куркыныч түгел иде, һәм алар фашистларның флангсына үтеп керделәр. Бу алымнары аларга дошманны тар-мар итәргә ярдәм итте.



Геройның әтисе Нурулла





Гали Шәмсетдиновның энесе Тәлгат тормыш иптәше Дания белән.

Гали Шәмсетдиновның сеңелесе Дамирә апа Казанда бүгенгесе көндә гаиләсе белән исән-сау гына гомер кичерә.

Галинең бертуган сеңелесе Миннебикә апа



## “Гыйбрәтле язмыш иясе.”

*Рәйсә апаны 17 яше дә тулмыйча сугышка алалар. Яүширмә авылыннан яу кырына киткән бердәнбер хатын-кыз була ул.Беренче чыныгуны ул Украина фронтында ала. Аннан икенче Белоруссия фронтына күчерелә. 1945 нче елның июнь ахырында авылына кайта.Күкрәгендә медальләр-кече лейтенантның батырлык билгесе.*








*Сугыш ветераннары һәйкәл янында*.







*Гүр иясе булып аусагыз да,*
*Әҗәл белми сездәй батырлар.*
*Утта янып көлгә калсагыз да,*
*Һәйкәл куя сезгә гасырлар.*





*Үлгәннәрнең каберен,*
*Исәннәрнең кадерен бел*



*Без үз кулларыбыз белән*
*Төзибез гүзәл тормыш.*
*Без тыныч ил төзүчеләр,*
*Кирәкми безгә сугыш!*







*Син борчылма күңел, яз килер,*
*Кыр казлары кайтыр күлләргә,*
*Безне котлап, иркен болында,*
*Моң чакырып бөек үрләргә.*







*Җиңү килде җирне нурга күмеп,*
*Шатлык белән күзне чылатып.*
*Килде ул көн горур күкрәкләрдә*
*Орден-медальләрне чыңлатып.*



*Бөек Җиңүгә*
*багышланган "Өчпочмаклы хатлар" исемле әдәби-*
*музыкаль кичә.*

Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

